КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 31 октябрь г.Казань № 975

Татарстан Республикасында үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төрләренең техник торышына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карага теркәлгән Татарстан Республикасында үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төрләренең техник торышына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасында үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төрләренең техник торышына күзәтчелек идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 31 октябрь, 975 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төрләренең техник торышына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе

1. Әлеге Татарстан Республикасында үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төренең техник торышына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон), Министрлар Советы – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төрләренең техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында» 1993 ел, 13 декабрь, 1391 нче карары нигезендә эшләнде һәм үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төрләренең техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә агросәнәгать комплексында төбәк дәүләт күзәтчелеген (ала таба – төбәк дәүләт күзәтчелеге) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен регламентлаштыра.

2. Юридик затлар, аларның җитәкчеләре һәм бүтән вазыйфаи затлары, шәхси эшмәкәрләр, аларның вәкаләтле вәкилләре (алга таба – юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр) тарафыннан 294-ФЗ номерлы Федераль законда, үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төрләренең техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә агросәнәгать комплексы өлкәсендә башка федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне бозуларны кисәтү, табып алу һәм кисәтү төбәк дәүләт күзәтчелеге предметы булып тора.

3. Төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы булып Татарстан Республикасында үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төрләренең техник торышына күзәтчелек идарәсе (алга таба – Идарә) тора.

4. Идарәнең төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары түбәндәгеләр:

Идарә башлыгы - Татарстан Республикасының баш дәүләр инженер-инспекторы;

Идарә башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасының баш дәүләр инженер-инспекторы урынбасары;

Идарәнең күзәтчелек һәм автоматлаштырылган исәпкә алу бүлеге башлыгы һәм вазыйфаи затлары, алар тиешенчә баш дәүләт инженер-инспекторы һәм дәүләт инженер-инспекторлары булып тора;

Идарәнең территориаль бүлекләре башлыклары (алга таба – территориаль бүлекләр), алар баш дәүләт инженер-инспекторлары булып тора;

территориаль бүлекләр консультантлары, алар баш дәүләт инженер-инспекторлары булып тора.

5. Идарәнең вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә хокуклы:

тракторлар, үзйөрешле юл-транспорт һәм бүтән машиналар һәм аларга прицепларның (Россия Федерациясенең Кораллы Көчләре һәм Россия Федерациясенең башка гаскәрләре машиналарыннан, шулай ук Экология, технология һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәт (Ростехнадзор) контролендә булган машиналар параметрларынна тыш) файдалану процессында гомер, кешеләр һәм мөлкәт сәламәтлеге, әйләнә-тирә мохитне саклау өчен иминлек тәэмин итү өлешендә техник торышын контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

тикшерүләр нәтиҗәләре буенча актлар төзергә, аларны танышу өчен юридик затка, шәхси эшмәкәргә тапшырырга;

юридик затка, шәхси эшмәкәргә ачыкланган бозуларны бетерү турында, аларны бетерү вакытларын күрсәтеп һәм (яки) гомергә, кешеләр сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт мөлкәтенә зыян турында, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтү чаралары, шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны бетерү буенча чаралар үткәрү турында үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирергә;

административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә һәм административ хокук бозулар турында эшләр буенча производствода катнашырга;

оешмалар җитәкчеләре белән килештереп төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру, машиналарның һәм җиһазларның техник торышын һәм Идарәнең башка функцияләрен бәяләү белән бәйле эшләр үткәрү өчен белгечләр җәлеп итәргә;

техник торышлары әйләнә-тирә мохитне саклау таләпләренә туры килмәгән яки куркынычсызлык таләпләренә туры килмәгән күзәтчелектәге үзйөрешле машиналарны һәм техниканың башка төрләрен эксплуатацияләүне тыярга;

дәүләт технологик күзәтчелеге органнары компетенциясенә керә торган һәм мондый карарлар кабул итү хокукы булган органнарның (оешмаларның) өстәмә карарын таләп итә торган мәсьәләләр буенча ачыкланган бозуларны бетерү турында мәбүри карап тикшерелергә тиешле күрсәтмәләрне җибәрергә;

оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан алар Идарә күзәтчелегендәге машиналар һәм җиһазларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм нормаларын саклау турында белешмәләрне, ә мәҗбүри иминиятләнергә тиеш күзәтчелектәге транспорт чаралары буенча, тагын мәҗбүри иминиятләү шартнамәләре буенча мәгълүматлар, мәҗбүри иминиятләү буенча статистик һәм бүтән мәгълүматларны билгеләнгән тәртиптә соратырга һәм алырга;

тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә алар карамагында әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат булган бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнары яик җирле үзидарә органнары ведомствосындагы оешмалардан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документлар һәм (яки) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати багланышлар кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән вакытта һәм тәртиптә соратырга һәм алырга.

6. Төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда Идарәнең вазыйфаи затлары Татарстан Республикасы прокуратурасы органнары, экспертлар, эксперт оешмалар, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән багланышка керә.

Төбәк дәүләт күзәтчелеген оештырганда һәм гамәлгә ашырганда Идарә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә аттестацияләнгән экспертларны, аккредитацияләүнең илкүләм системасында аккредитацияләү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә аккредитацияләнгән, тикшерү хткәрелә торган юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән граждан-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормый торган һәм тикшерелә торган затның аффилләшкән затлары булмаган эксперт оешмаларын җәлеп итәргә хокуклы.

7. Төбәк дәүләт контролен тормышка ашырганда административ процедуралар тәртибе, вакытлары һәм эзлеклелеге Идарә тарафыннан агросәнәгать комплексында гомер, кешеләр һәм мөлкәт сәламәтлеге, әйләнә-тирә мохитне саклау өчен куркынычсызлыкны тәэмин итү өлешендә машиналар һәм җиһазларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен, шулай ук стандартлар, норматив документлар белән регламентлана торган кагыйдәләрне саклауга дәүләт күзәтчелеге буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламенты белән билгеләнә.

8. Төбәк дәүләт контроле юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы (документар һәм (яки) күчмә) һәм планнан тыш (документар һәм (яки) күчмә) тикшерүләр оештыру һәм үткәрү, мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау буенча чаралар, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр белән багланышларсыз гамәлгә ашырыла торган контрль чаралары оештыру һәм үткәрү, ачыкланган бозулар нәтиҗәләрен кисәтү һәм (яки) бетерү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чаралар күрү, мәҗбүри таләпләрне үтәүне системалы күзәтү, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне үтәү торышын анализлау һәм фаразлау ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

Планлы тикшерүләр 294-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә үткәрелә.

Планнан тыш тикшерүләр 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясында каралган нигезләр буенча үткәрелә.

Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр документар һәм (яки) күчмә тикшерүләр формасында үткәрелә.

үзйөрешле машиналарны һәм техниканың башка төрләрен эксплуатацияләү процессында аларны планлы (рейд) караулар, тикшерүләр 294-ФЗ номерлы Федераль законның $13^2$ статьясы нигезендә планлы (рейд) биремнәре нигезендә үз компетенциясе кысаларында вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан үткәрелә.

Мондый биремнәрне рәсмиләштерү тәртибе һәм аларның эчтәлеге, планлы (рейд) караулар, тикшерүләр нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе Идарәнең норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

Тикшерүләр 294-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә чыккан Идарә башлыгы  боерыгы нигезендә үткәрелә.

9. Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү 294-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

10. Идарәнең вазыйфаи затлары төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда 294-ФЗ номерлы Федераль законда, 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыккан бүтән норматив хокукый актларда билгеләнгән чикләүләрне сакларга һәм йөкләмәләрне үтәргә тиеш.

11. Төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең хокуклары бозылуга китергән идарәнең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.